**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге составына керүче Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

18 ноябрь, 2022 ел №1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 7 декабрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 группа мөмкинчелекләре чикләнгән һәм 80 яшьтән өлкән гражданнардан гайре, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

– Югары Тегермәнлек торак пунктында урам утларын карап тоту (тору) һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Югары Тегермәнлек авылының Фрунзе, Титов урамнарындагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, аны ташуга транспорт хезмәтләре, вак ташны түшәү, хезмәткә түләү);

– Югары Тегермәнлек авылында урамнарның юл йөрү өлешләрен карап тоту (тору) (шартнамә нигезендә эш өчен һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

– Югары Тегермәнлек авылында суүткәргечне ремонтлау һәм су белән тәэмин итү системаларын Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эш өчен һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

– Кадастровый номеры 16:34:160901:72 булган гидротехник корылма өчен деклорация ясау;

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы
А.Ш.Альмиев